**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

28.10.2016 № 1201-п

«Татарстан Республикасы территориясендә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге, урман фонды, махсус саклanучы территорияләрдәге һәм объектлардагы җирләр өчен ачык соры урман, соры урман, куе соры урман туфракларында һәм җиңелчә һәм уртача балчыксыл туфракларда, урман фонды җирләре өчен кара туфраклы типик авыр балчыксыл һәм балчыксыл туфракларда, махсус саклануч табигый территорияләрдәге һәм объектлардагы җирләр өчен кара туфраклы көлсуланган, кара туфраклы типик, куе соры урман, кәсле-карбонат белән эрегән, кәсле-көлсу авыр балчыксыл һәм балчыклы туфракларда рекультивацияләү һәм башка төрле торгызу эшләрен үткәргәннән соң нефтьнең һәм аның трансформациясе продуктларының мөмкин булган калдык өлеше» төбәк нормативларын раслау турында

2002 елның 10 гыйнварындагы «Әйләнә-тирәлекне саклау турында» № 7-ФЗ Федераль законның 6 статьясын үтәү максатында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 6 июлендәге «Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы мәсьәләләре» № 325 карары белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 2013 елның 10 июлендәге «Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы тарафыннан туфракларның төбәк сыйфат нормативларын билгеләү турында» № 382-п боерыгы нигезендә, хуҗалык яки башка төрле эшчәнлекнең әйләнә-тирәлеккә булган йогынтысын җайга салу максатларында боерык бирәм:

1. «Татарстан Республикасы территориясендә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге, урман фонды, махсус саклanучы территорияләрдәге һәм объектлардагы җирләр өчен ачык соры урман, соры урман, куе соры урман туфракларында һәм җиңелчә һәм уртача балчыксыл туфракларда, урман фонды җирләре өчен кара туфраклы типик авыр балчыксыл һәм балчыксыл туфракларда, махсус саклануч табигый территорияләрдәге һәм объектлардагы җирләр өчен кара туфраклы көлсуланган, кара туфраклы типик, куе соры урман, кәсле-карбонат белән эрегән, кәсле-көлсу авыр балчыксыл һәм балчыклы туфракларда рекультивацияләү һәм башка төрле торгызу

эшләрен үткәргәннән соң нефтьнең һәм аның трансформациясе продуктларының мөмкин булган калдык өлеше» төбәк нормативларын (алга таба – НПМКӨ төбәк нормативлары) кушымтага туры китереп расларга.

2. Шушы Боерык бастырып чыгарылган вакыттан башлап вәкаләтле федераль дәүләт хакимияте органнары тарафыннан тиешле әйләнә-тирәлек сыйфаты нормативлары кертелгәнчегә кадәр НПМКӨ төбәк нормативлары өчен гамәлдә булу вакытын билгеләргә.

3. Хокукый тәэминат бүлегенә (М.Р. Галиәкбәров) шушы Боерыкның дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

4. Бу Боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары Р.И. Камаловны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр в.б. Р.И. Камалов

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 2016 елның «28» октябрендә № 1201-п боерыгы белән расланды

**“Татарстан Республикасы территориясендә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге, урман фонды, махсус сакланучы территорияләрдәге һәм объектлардагы җирләр өчен ачык соры урман, соры урман, куе соры урман туфракларында һәм җиңелчә һәм уртача балчыксыл туфракларда, урман фонды җирләре өчен кара туфраклы типик авыр балчыксыл һәм балчыксыл туфракларда, махсус сакланучы табигый территорияләрдәге һәм объектлардагы җирләр өчен кара туфраклы көлсуланган, кара туфраклы типик, куе соры урман, кәсле-карбонат белән эрегән, кәсле-көлсу авыр балчыксыл һәм балчыклы туфракларда рекультивацияләү һәм башка төрле торгызу эшләрен үткәргәннән соң нефтьнең һәм аның трансформациясе продуктларының мөмкин булган калдык өлеше” төбәк нормативлары**

1. Әйләнә-тирәлекнең сыйфат нормативларына карый торган “Татарстан Республикасы территориясендә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге, урман фонды, махсус сакланучы территорияләрдәге һәм объектлардагы җирләр өчен ачык соры урман, соры урман, куе соры урман туфракларында һәм җиңелчә һәм уртача балчыксыл туфракларда, урман фонды җирләре өчен кара туфраклы типик авыр балчыксыл һәм балчыксыл туфракларда, махсус сакланучы табигый территорияләрдәге һәм объектлардагы җирләр өчен кара туфраклы көлсуланган, кара туфраклы типик, куе соры урман, кәсле-карбонат белән эрегән, кәсле-көлсу авыр балчыксыл һәм балчыклы туфракларда рекультивацияләү һәм башка төрле торгызу эшләрен үткәргәннән соң нефтьнең һәм аның трансформациясе продуктларының мөмкин булган калдык өлеше” төбәк нормативлары (алга таба – НПМКӨ төбәк нормативлары) Россия Федерациясе Табигый ресурслар министрлыгының 12.09.2002 № 574 боерыгы белән расланган Рекультивацияләү һәм башка төрле торгызу эшләрен үткәргәннән соң туфракларда нефтьнең һәм аның трансформациясе продукталырының мөмкин булган калдык өлеше нормативларын эшләү һәм гамәлгә кертү буенча вакытлы күрсәтмәләр нигезендә, Татарстан Республикасындагы җирдән файдалану төрен һәм туфракларның классификациясен исәпкә алып (1-3 таблица) эшләнде һәм Татарстан Республикасы территориясендә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге, урман фонды, махсус сакланучы территорияләрдәге һәм объектлардагы җирләр өчен ачык соры урман, соры урман, куе соры урман туфракларында һәм җиңелчә һәм уртача балчыксыл туфракларда, урман фонды җирләре өчен кара туфраклы типик авыр балчыксыл һәм балчыксыл туфракларда, махсус сакланучы табигый территорияләрдәге һәм объектлардагы җирләр өчен кара туфраклы көлсуланган, кара туфраклы типик, куе соры урман, кәсле-карбонат белән эрегән, кәсле-көлсу авыр балчыксыл һәм балчыклы туфракларда рекультивацияләү һәм башка төрле торгызу эшләрен үткәргәннән соң нефтьнең һәм аның трансформациясе продуктларының мөмкин булган калдык өлешен билгели.

2. НПМКӨ төбәк нормативлары туфракларның һәм җирләрнең нефть углеводородлары белән пычрану дәрәҗәсен чикләү һәм регламентлау, туфрак экосистемаларына тискәре йогынтыны юкка чыгару, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә уңдырышлылыкны һәм үстерелә торган продуктларның сыйфатын саклау максатларында билгеләнә.

3. НПМКӨ төбәк нормативлары контрольлектә тотучы органнар һәм хуҗалык итүче субъектлар тарафыннан рекультивацияләү һәм башка төрле торгызу эшләре үткәрелгәннән соң туфракларның һәм җирләрнең торышын бәяләгәндә файдалану өчен билгеләнә.

4. НПМКӨ төбәк нормативлары туфрактагы нефть продукталырының нефть углеводородларының ГОСТ 17.0.0.02-79 "Табигатьне саклау. Атмосфераның, җир өсте суларының һәм туфракның пычрану дәрәҗәсен контрольдә тотуны метрологик тәэмин итү. Төп нигезләмәләр", РД 52.18.575-96 "Инфракызыл спектрометрия ысулы белән туфрак үрнәкләрендә нефть продуктларының тулай өлешен ачыклау" һәм ГОСТ 26423-85 "Туфраклар. Чагыштырма электр үткәрүчәнлеген, pH һәм су сыгынтысының тыгыз калдык өлешен билгеләү методлары" нигезендә ачыкланган ПНД Ф 16.1:2.2.22-98 "ИК-спектрометрия ысулы белән минерал, органоген, органик-минерал туфракларда һәм су төбе утырмаларында нефть продуктларының массакүләм өлешен ҮБМ" нигезендә билгеләнгән массакүләм өлешеннән чыгып исәпләнгән өлешенә тигез итеп кабул ителә.

Туфраклар ГОСТ 17.4.3.01-83 "Табигатьне саклау. Туфраклар. Туфракларны сайлап алуга карата гомуми таләпләр", ГОСТ 17.4.4.02-84 "Табигать саклау. Туфраклар. Химик, бактериологик, гельминтологик анализ ясау өчен үрнәкләрне сайлап алу һәм әзерләү методлары", ГОСТ 28168-89 "Туфраклар. Үрнәкләрне сайлап алу" нигезендә сайлап алына.

1 таблица

## “Татарстан Республикасы территориясендә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге, урман фонды, махсус сакланучы территорияләрдәге һәм объектлардагы җирләр өчен ачык соры урман, соры урман, куе соры урман туфракларында һәм җиңелчә һәм уртача балчыксыл туфракларда, урман фонды җирләре өчен кара туфраклы типик авыр балчыксыл һәм балчыксыл туфракларда, махсус сакланучы табигый территорияләрдәге һәм объектлардагы җирләр өчен кара туфраклы көлсуланган, кара туфраклы типик, куе соры урман, кәсле-карбонат белән эрегән, кәсле-көлсу авыр балчыксыл һәм балчыклы туфракларда рекультивацияләү һәм башка төрле торгызу эшләрен үткәргәннән соң нефтьнең һәм аның трансформациясе продуктларының мөмкин булган калдык өлеше” төбәк нормативлары

| Туфраклар | | | | Туфрак горизонтлары (индексы) яки катламнары (тирәнлекләре) | Норматив мәгънәсе, г/кг | Рекультивацияләнгән кишәрлекне кабул итү таләпләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Надтип төркеме | Гранула-метрик составы | Коды | Типлары | | | Норматив мәгънәсе арттырылган мөмкин булган мәйданы (рекультивацияләнгән кишәрлек мәйданының %ы) | Өстәмә таләпләр (кирәк булганда) |
| 1. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирәр (Код 1)<br>Урман-дала зонасы (Код 06) | | | | | | | |
| Органик-минерал | Җиңелчә һәм уртача балчыксыл | 22 | Ачык соры урман | Aпах, Al | 2,0 | 10 | Гомуми тоз күләме (су сыгынтысының тыгыз калдык өлеше) 0,15% югары түгел |
| Органик-минерал | Җиңелчә һәм уртача балчыксыл | 22 | Соры урман | Aпах, Al | 2,5 | 10 | Гомуми тоз күләме (су сыгынтысының тыгыз калдык өлеше) 0,15% югары түгел |
| Органик-минерал | Җиңелчә һәм уртача балчыксыл | 22 | Куе соры урман | Aпах, Al | 2,8 | 10 | Гомуми тоз күләме (су сыгынтысының тыгыз калдык өлеше) 0,15% югары түгел |
| 2. Урман фонды җирләре (Код 2)<br>Урман-дала зонасы (Код 06) | | | | | | | |
| Органик-минерал | Җиңелчә һәм уртача балчыксыл | 22 | Ачык соры урман, соры урман, куе соры урман | Al | 5,0 | 10 | Гомуми тоз күләме (су сыгынтысының тыгыз калдык өлеше) 0,15% югары түгел |
| Органик-минерал | Авыр балчыксыл һәм балчык | 23 | Типик кара туфраклар | Al | 5,0 | 10 | Гомуми тоз күләме (су сыгынтысының тыгыз калдык өлеше) 0,15% югары түгел |
| 3. Махсус сакланучы территорияләр һәм объектлар (Код 6)<br>Урман-дала зонасы (Код 06) | | | | | | | |
| Органик-минерал | Җиңелчә һәм уртача балчыксыл | 22 | Ачык соры урман, соры урман, куе соры урман | Al | 2,0 | 10 | Гомуми тоз күләме (су сыгынтысының тыгыз калдык өлеше) 0,15% югары түгел |
| Органик-минерал | Авыр балчыксыл һәм балчык | 23 | Кәсле-көлсу, куе соры урман, кәсле-карбонат белән көлсуланган, кәсле-карбонат белән эретелгән, көлсуланган кара туфраклар, типик кара туфраклар | Al | 2,0 | 10 | Гомуми тоз күләме (су сыгынтысының тыгыз калдык өлеше) 0,15% югары түгел |

2 таблица

Туфрак горизонтларын индексацияләү

| Туфрак горизонты индексы | Туфрак горизонтының атылышы |
|---|---|
| Ao | өске туфрак катламы (урман түшәмәсе) |
| Aт | каты черемәле, торфлы катлам |
| Ad | кәс |
| Al | черемәле, кәсле катлам |
| Aпах | сукалау катламы |
| A2 | көлсу горизонт (ашалмалар) |
| B | иллювиаль катлам (юылулар) |
| Bh | иллювиаль-черемәле горизонт |
| Bf | иллювиаль-тимерле горизонт |
| T | төрле катлаулылык дәрәҗәсендәге торфлы горизонт |
| Оч | чүбек (тере мүкләрнең һәм мүк киезләренең өске катламы) |

3 таблица

<table>
<tr><td colspan="3">Табигый-климат зоналары кодлары</td></tr>
<tr><td colspan="2">Табигый-климат зонасы</td><td>Коды</td></tr>
<tr><td colspan="2">Субарктика</td><td>01</td></tr>
<tr><td colspan="2">Тундра һәм урман-тундра</td><td>02</td></tr>
<tr><td colspan="2">Төньяк тайга</td><td>03</td></tr>
<tr><td colspan="2">Урта тайга</td><td>04</td></tr>
<tr><td colspan="2">Көньяк тайга</td><td>05</td></tr>
<tr><td colspan="2">Урман-дала</td><td>06</td></tr>
<tr><td colspan="2">Дала</td><td>07</td></tr>
<tr><td colspan="2">Коры дала</td><td>08</td></tr>
<tr><td colspan="2">Ярым-чүл</td><td>09</td></tr>
<tr><td colspan="2">Субтропик</td><td>10</td></tr>
<tr><td colspan="3">Җирләрне рекультивацияләү юнәлеше кодлары</td></tr>
<tr><td colspan="2">Рекультивацияләү юнәлеше</td><td>Коды</td></tr>
<tr><td colspan="2">Авыл хуҗалыгы</td><td>1</td></tr>
<tr><td colspan="2">Урман хуҗалыгы</td><td>2</td></tr>
<tr><td colspan="2">Су хуҗалыгы</td><td>3</td></tr>
<tr><td colspan="2">Рекреацияләү</td><td>4</td></tr>
<tr><td colspan="2">Төзү</td><td>5</td></tr>
<tr><td colspan="2">Табигатьне саклау</td><td>6</td></tr>
<tr><td colspan="2">Санитар</td><td>7</td></tr>
<tr><td colspan="3">Надтип төркемнәренең кодлары</td></tr>
<tr><td>Надтип төркеме</td><td>Төркем эчендәге үзенчәлекләр</td><td>Коды</td></tr>
<tr><td>Органоген туфраклар</td><td>Өслекле<br>Түбән</td><td>11<br>12</td></tr>
<tr><td>Табигый органоминерал һәм антропоген үзгәртелгән туфраклар</td><td>Ком белән комлы туфрак<br>Җиңелчә һәм уртача балчыксыл<br>Авыр балчыксыл һәм балчык</td><td>21<br>22<br>23</td></tr>
<tr><td>Антропоген туфракка охшаш ясалмалар</td><td>Ком белән комлы туфрак<br>Җиңелчә һәм уртача балчыксыл<br>Авыр балчыксыл һәм балчык</td><td>31<br>32<br>33</td></tr>
<tr><td>Минерал грунтлар</td><td>Ком белән комлы туфрак<br>Җиңелчә һәм уртача балчыксыл<br>Авыр балчыксыл һәм балчык</td><td>41<br>42<br>43</td></tr>
</table>